Тукай муниципаль районы
Иске Абдул авыл җирлеге
Иске Абдул авылы

ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

«27» ноябрь 2024 ел № 01

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Иске Абдул авылы гражданнар жыены

КАРАР БИРДЕ:

1. «2025 елда яшәү урыны буенча Иске Абдул авыл жирлеге Иске Абдул авылы территориясендә теркәлгән һәр балигь булган кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (икә йөз илле) сум күләмендә билгеләргә һәм өлешчә мобилизацияләү буенча РФ Коралы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарны, аларның гаилә әгъзаларын үзара салым буенча взносларны түләүдән азат итәргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләне хәл итүгә юнәлтергә:
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Иске Абдул авылы юлларын ремонтлау вак таш сатып алу);
- урамнарны яктырту жайланмасы (Электроматериаллар сатып алу, Иске Абдул авылында урамнарны яктырту челтәрләрен монтажлау һәм урнаштыру).

2. Тукай муниципаль районы Иске Абдул авыл жирлеге Иске Абдул авылы гражданнар жыены нәтиҗәсен авыл жирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка житкерергә.

3. Тукай муниципаль районы Иске Абдул авыл жирлеге Иске Абдул авылы гражданнар жыены нәтиҗәсен Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл жирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

Гражданнар жыенында рәис[illegible]учә,
Иске Абдул авыл жирлеге Б[illegible] Р.Х.Сафина